| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

РАСПОРЯЖЕНИЕ БОЕРЫК

«02» март 2026 ел № 443-р

**2026 елга гражданнарның керемнәре һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясе чикләрен билгеләү турында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 49 статьясы нигезендә «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм югарыда аталган законга кушымтада бәян ителгән салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен билгеләү методикасына нигезләнеп, Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Социаль наем шартнамәсе буенча торак урын мәйданының исәп нормасы һәм торак урын мәйданын бирү нормасы турында» 2021 елның 23 апрелендәге 395 номерлы карары белән, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты боерык бирә:

1. 2026 елга гражданнарны аз керемле дип тану турында карар кабул итү өчен түбәндәге чикләрне расларга:

1.1. Гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче һәм салым салынырга тиешле милек бәясе чиге:

1.1.1. ялгыз яшәүче граждан өчен – 820 998 сум;

1.1.2. ике кешедән торган гаилә өчен – 1 641 996 сум;

1.1.3. өч кешелек гаилә өчен – 2 462 994 сум;

1.1.4. дүрт кешедән торган гаилә өчен – 3 283 992 сум;

1.1.5. биш кешелек гаилә өчен – 4 104 990 сум;

1.1.6. алты кешелек гаилә өчен – 4 925 988 сум;

1.1.7. җиде кешелек гаилә өчен – 5 746 986 сум;

1.2. Гаиләнең һәр әгъзасына туры килгән уртача айлык гомуми керем күләме:

1.2.1. ялгыз яшәүче граждан өчен – 26 651,76 сум;

1.2.2. ике кешедән торган гаилә өчен – 26 651,76 сум;

1.2.3. өч һәм аннан да күбрәк кешеле гаилә өчен – 26 651,76 сум

2. Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының Иҗтимагый торак комиссиясенә 1.1 һәм 1.2. пунктчаларында күрсәтелгән чик күрсәткечләрен торак биналарга мохтаҗ буларак гражданнарны исәпкә куюда әлеге карарны кулланырга.

3. Әлеге боерык үз көченә кергән вакыттан «2025 елга гражданнар кеременең һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен билгеләү

турында» 2025 елның 17 мартындагы 302-р номерлы боерыкны үз көчен югалткан дип санарга.

4. Әлеге боерыкны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин